**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

28.03.2020 № 139

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 мартындагы ММ-П36-1945 номерлы йөкләмәсен үтәү максатында:

1. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) тормышка ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 2020 елның 1 маена кадәр гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә куркыныч янау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү сәбәпле уздырыла торган планнан тыш тикшерүләр, аларны уздыру нәтиҗәсендә рөхсәт кәгазьләре, лицензияләр, аккредитация узу турында аттестатлар һәм рөхсәт бирү характерындагы башка документлар бирелә торган тикшерүләрдән тыш, аларга карата «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланылучы тикшерүләр уздыруны туктатып торырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм «Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектлары төзүдә өлешле катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, тикшерүләр уздыруны кыскарту механизмын эшләргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына 2020 елның 1 маена кадәр муниципаль берәмлекләр территориясендә тикшерүләр оештыруга һәм уздыруга вәкаләтле Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә куркыныч янау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү сәбәпле уздырыла торган планнан тыш тикшерүләр, аларны уздыру нәтиҗәсендә рөхсәт кәгазьләре, лицензияләр, аккредитация узу турында аттестатлар һәм рөхсәт бирү характерындагы башка документлар бирелә торган тикшерүләрдән тыш, аларга карата «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-

ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланылучы тикшерүләр уздыруны туктатып торырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**